# *Сулыш  һәм сөйләм*

**Логопед  Шарафутдинова Л.Д.**
**Мөслим “Миләшкәй”балалар бакчасы**

Балада ана карынында ук барлыкка килгән патологияләр

Нәселдән килә торган авырулар

Бала туганда алган травмалар

Баш миенең функциональ эшчәнлегенә зыян килү

Социаль-көнкүреш шартларының, экологиянең начар булуы

Аваз - сөйләм органнарының эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килә. Кешенең сөйләм барлыкка китерә торган органнары җыелмасын ***сөйләм аппараты*** диләр.



**Сөйләм аппаратының өлешләре:**

1) сулыш аппараты: аңа диафрагма, үпкәләр, бронхлар һәм сулыш юлы (трахея) керә;

2) тавыш ярыларыннан һәм кимерчәкләрдән гыйбарәт булган бугаз;

3) бугаздан өске өлеш; аңа йоткылык, авыз һәм борын куышлыклары керә.



Авазлар ясауда барлык органнар да катнаша. Сулыш органнары, авазлар ясалсын өчен, һава дулкыны бирәләр, аны төрлечә үзгәртәләр.

Һәр авазны әйткәндә, диафрагма төшеп, күтәрелеп тора ; бронхлар да диафрагма белән ярашып эшлиләр, шулай итеп бу авазларның үзенчәлеген, иҗекләргә бүлүне тәэмин итә. Сулыш аппараты сулыш алу һәм сулыш чыгару өчен җайланган. Ул авазларны ясауда катнаша, ләкин аларның ясалу урыны була алмый.



**Үпкә** - сөйләү вакытында аеруча актив катнашучы органнар арасында аеруча әһәмиятлесе.

Сулыш ике төрле була: аскы һәм өске сулыш. Өске сулыш булганда үпкәнең өске өлеше генә һава белән тутырыла. Бу кешенең организмын кислород белән тәэмин итүдә үпкәнең бөтен өлеше дә катнашмый. Аскы сулыш алу төрле яклап файдалы. Бу вакытта үпкәнең бөтен җире дә, кабыргалар да хәрәкәткә килә.



Сөйләм вакытында үпкәдә һәрвакыт ниндидер күләмдә һава запасы булырга тиеш. Моның өчен махсус күнегүләр үткәрү, ничек сулыш алуыңа даими игътибарлы булу кирәк.

Дөрес сулыш алу сөйләгәндә бик әһәмиятле. Ләкин аның әһәмияте моның белән генә бетми әле. Без һәрвакыт балаларның сөйләме камил, матур, дөрес булуы турында кайгыртырга тиешбез. Моңа дөрес сулыш алу, тавышны рациональ файдалану нәтиҗәсендә генә ирешеп була.



Бала организмын чыныктыру ысуллары арасыннан кызыклы, үзенчәлекле,уңайлы формалары булып:

***сулыш гимнастикасы***

тора.

# Сулыш гимнастикасын дөрес ясау кагыйдәләре:

1. Борын белән кыска сулыш алырга, җилкәләрне күтәрмәскә.
2. Сулыш озын һәм салмак булырга тиеш.
3. Сулышны алган саен авыз аша чыгарырга.
4. Сулыш алуны хәрәкәт белән бергә башкарырга.
5. Битләрне кабартмаска.
6. Гимнастиканы утырып та,басып та эшләргә була.
7. Күнегүләрне 3-5 тапкыр кабатлагач җитә, күп эшләсәң, баш әйләнүе бар.
8. Берничә шөгыльдән соң күнегүләрне катлауландырырга була.

И.С.Красикованың элементар сулыш күнегүләрен куллану бик отышлы:”Уч төбеңә өр” “Шар кабарт”.

М.Лазаревның сулыш алу ысулы да бик үзенчәлекле. Аның ысулы буенча һәр аваз да аерым чыныктыруга тәэсир итә. Аның ысулы “Терелтүче авазлар” дип атала.

А.Н.Стрельникованың сулыш гимнастикасы ысулы да үзенә бер төрле Анда сулыш хәрәкәтләр белән алып барыла.















**С**улыш күнегүе сөйләм үсеше өчен әһәмиятле.

-авазлар әйтелешенә кирәкле һава агымын формалаштыру өчен бала **с**улыш күнегүе аша нечкә агым белән өрергә өйрәнә;

-- сөйләм вакытындагы сулышның житешсезлекләрен җиңәргә ярдәм итә;

--бер фразаны җиңел генә әйтеп бирү өчен һаваны авыз аша салмак кына чыгаруга ирешә;

-сөйләм вакытында дөрес суларга өйрәнү, кимчелеге төзәтелгән авазларны ныгытуда да ярдәм итә;

-дөрес сулыш алу, тавышны рациональ файдалану нәтиҗәсендә генә сөйләмебезнең камил, матур, дөрес булуына ирешеп була.

# ИГЪТИБАРЫГЫЗ ӨЧЕН РӘХМӘТ!